ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СРЕДНЕАТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 2а, д.Нижние Аты ,
Арский муниципальный район, 422016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк урам, 2а йорт, Түбән Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422016

Тел. (84366) 50-7-35, факс (84366) 50-7-35 E-mail: Sat.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

# КАРАР

**22 ноябрь 2018 ел** **№26**

**“Урта Аты авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федраль законы, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, “Урта Аты авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге уставы белән , җирле референдумда кабул ителгән 2018 елның 18 нче нояберендәге 6 нчы номерлы карарны гамәлгә ашыру максатыннан, Урта Аты авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. “Урта Аты авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыюның әлеге тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында бастырып чыгарырга, Арча муниципаль районы рәсми сайтында һәм Урта Аты авылы, Узәк урамы , 37 йорт, Урта Сәрдә авылы, Узәк урамы, 70А йорт адреслары буенча халыкның күпләп җыелу урыннарындагы мәгълүмат такталарына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җирлек башлыгы Батталова Р.Х

Урта Аты авыл җирлеге
башкарма комитетының
2018 елның 22 нче нояберендәге
26 нче номерлы
карарына 1 нче
кушымта

**“Урта Атыавыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип “Урта Аты авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Үзара салым акчасы 18 яшькә җиткән һәм Урта Аты авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан, җирле референдумда катнашу-катнашмауга, тавыш бирү барышында белдергән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә 2019 елның 21нчы февраленә кадәр түләнә.

3. Гражданнарның аерым категорияләре өчен:

а)80 яшьтән югары гражданнарга;

б)уку йортларында көндезге бүлектә укучы студентларга

түләү күләме җирле референдум карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

4. Түбәндәге игътибарга лаеклы сәбәпләр булганда:

а) гаилә әгъзасының (эти-әнисе, тормыш иптәше, балалары) үлеме,

б) янгыннан һәм бәлә-казадан зыян күрү,

өч айдан артык булмаган вакытка, түләү кертүне кичектереп тору рөхсәт ителергә мөмкин.

5. Бер тапкыр түләнә торган түләүне башкару турындагы белдерү кәгазе бланкы гражданнар игътибарына Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында бастырып чыгару, Урта Аты авылы, Узәк урамы , 37 йорт, Урта Сәрдә авылы, Узәк урамы, 70А йорт адреслары буенча халыкның күпләп җыелу урыннарындагы мәгълүмат такталарына урнаштыру, шулай ук имза куйдырып шәхсән тапшыру яки почта элемтәсе аша халыкка җиткерелә.

Белдерү кәгазе үз эченә гражданнарның үзара салым акчаларын түләү реквизитларын, бер тапкыр түләнә торган акчаның тулысынча яки киметелгән күләмдәге суммасын, түләү вакытын алырга тиеш.

6. Гражданнардан алынган үзара салым акчалары “Урта Аты авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге шәхси хисабына күчерелә.

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыруга һәм почта аша күчерүгә хокуклы оешмалар, Урта Аты авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы, https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт

хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша башкарыла.

8. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаган башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

9. Билгеләнгән вакытта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Урта Аты авыл җирлеге
башкарма комитетының
2018 елның 22 нче нояберендәге
26 нче номерлы
карарына 2 нче
кушымта

Урта Аты авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге
бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү кертү
турында
БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ № ______

Түләүченең Ф.И.Ә.И.
______________________________________________________________
Адресы:_______________________________________________________
Нигезләмә:_____________________________________________________
Сезгә ________________________ кадәрге вакыт эчендә ________________________________________ чараны гамәлгә ашыру буенча _____________ сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләүне түбәндәге реквизитларга күчерергә кирәк:
Кабул итүче як банкы БИК _____________________________________
Сч. № ________________________________________________________
Кабул итеп алучы Сч. № _______________________________________
ИНН __________________________________________
КПП __________________________________________
КБК _______________ОКАТО __________________
Түләүнең билгеләнеше__________________________________________
Җитәкче __________________ ___________________________________
М.У. (имза) (тулысынча язылыш)

---------------------- -- **кисеп алу сызыгы** ------------------

"Урта Аты авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне _________________ сум күләмендә түләү турында № ________ белдерү кәгазе.
Түләүченең Ф.И.Ә.И.
______________________________________________________________
Адресы:_______________________________________________________
Кабул ителде «__» ____________ 20__ ел. ______________________________
(түләүченең имзасы/ фамилиясе)

*Искәрмә. Белдерү кәгазе түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, түләү кәгазе өлеше (отрывной корешок) тутырыла һәм Урта Аты авыл җирлеге башкарма комитетында кала.*